| Республика Татарстан<br>Совет Альметьевского сельского поселения Сармановского муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы |
| --- | --- |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10 июнь 2026 ел № 24

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге Советының 2020 елның 17 июнендәге 10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын кертү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында.

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль кануны, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге Уставы нигезендә Әлмәт авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге Советының 2020 елның 17 июнендәге 10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын кертү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә (05.04.2023 N 6 карары редакциясендә):

а) 2 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырган муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата, әгәр бу белешмәләрне бозу әһәмиятсез булса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:»;

б) 3 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Күрсәтелгән мәсьәләне карау өчен нигез булып муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) советка кергән гаризасы тора.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» халыкка җиткерергә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әлмәт авыл җирлеге Советы Рәисе Д.Ә.Газизов.